| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ИВАНОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИВАНОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 2023 елның 19 октябре | № 38 |

**“Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

8.2.3, 8.3.1 пунктларда «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.»;

9.5 пунктта «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

9 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 9.5.1 пункт өстәргә:

«9.5.1. Муниципаль хезмәткәрләргә 9.5 пунктында күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

19 нчы бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 19.4.15 пункты белән тулыландырырга:

«19.4.15.Муниципаль хезмәткәр «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, коррупциягә каршы тору максатларында башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу таләпләрен һәм бурычларны үтәмәгәне өчен, әгәр мондый чикләүләр, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган шартлар нәтиҗәсе булып танылса икән, җаваплылыктан азат ителә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Ивановка авылы, Яшьлек урамы, 5 нче йорт, Аккүл авылы, Колхоз урамы, 16Б йорт, Медведка авылы, Юл урамы, 32 нче йорт, Михайловка авылы, Үзәк урам, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Ивановка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе А.П.Бодряева